ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ЧИСТОПОЛЬСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН» РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ «ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

***Постановление*** ***Карар***

**2021 елның 11 феврале** **Чистай шәһәре** **№ 61**

Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 28 маендагы 277 номерлы карары белән расланган җир эшләрен җитештерүгә ордер бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Норматив хокукый актны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы министрлыклары һәм ведомстволарының бердәм коллеги-ясенең 2020 елда Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетын көтелгән үтәү йомгаклары һәм республиканың финанс, казначылык һәм 2021 елда салым ор-ганнарының 2021 елның 4 гыйнварындагы ПР-3 номерлы бурычлары буенча беркет-мәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 28 маендагы 277 номерлы карары белән расланган җир эшләрен җитештерүгә ордер бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «2. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты турында» бүлегенең 2.6 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булмау турында белешмә»;

1.2. «2. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты турында» бүлегенең 2.6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.14. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган бүлмәләргә, гариза бирүчеләрнең көтү һәм кабул итү урынына, шул исәптән Россия Федерациясенең инвалидларны социаль яклау турындагы законы | Муниципаль хезмәт күрсәтү янгынга каршы тору системасы һәм янгын сүндерү системасы, документлар тутыру өчен кирәкле җиһаз, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырылган биналарда һәм бүлмәләрдә башкарыла. Инвалидларның муниципаль хезмәт күрсәтү урынына каршылыксыз керүе (бинага чыгу һәм шул чикләрдә хәрәкәт | |

| | | |
|---|---|---|
| нигезендә әлеге объектларга инвалидлар өчен керү мөмкинлеген тәэмин итүгә, әлеге хезмәтләрне күрсәтү тәртибе турында визуаль, текст һәм мультимедиа мәгълүматын урнаштыруга һәм бизәүгә карата таләпләр | итү, транспорт чарасына утырту һәм аннан төшерү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып, инвалидларны күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү функциясе нык бозылган хәлдә озата баруы) тәэмин ителә.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматы мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла. Инвалидларның каршылыксыз керүен тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат чыганакларын тиешенчә урнаштыру, инвалидлар өчен кирәкле тавыш һәм күрү мәгълүматын, шулай ук рельефлы-ноктaлы Брайль шрифты белән башкарылган язуларны, билгеләр һәм башка текстлы һәм график мәгълүматны кабатлау, сурдопереводчикны һәм тифлосурдопереводчикны кертү.<br>Махсус укытуны раслаучы һәм формасы буенча бирелә торган һәм дәүләт сәясәтен эшләү һәм гамәлгә ашыру, халыкны социаль яклау өлкәсендә норматив-хокукый җайга салу функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә бирелүче документ булган озатучы этне кертү. | |

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары П.Б. Емельяновка йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов